**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

утыз бишенче утырыш

# КАРАРЫ

29 нчы октябрь 2024 ел **№ 271** Теләче ав.

Теләче муниципаль район Советының 2008 елның 22 августындагы 139/1 номерлы «Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарында гражданнарның муниципаль хезмәттән тигез файдалану өлешендә муниципаль хезмәтнең төп принципларын гамәлгә ашыру максатларында, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Теләче муниципаль район Советының 2008 елның 22 августындагы 139/1 номерлы карары (Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советының 13.11.2017 № 112, 30.06.2021 № 62 карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмәнең 6 пунктының а пунктчасына үзгәреш кертергә, түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«а) муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече, өлкән һәм әйдәүче төркемнәренә караган муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләгәндә җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча.;».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Теләче муниципаль
районы башлыгы А.Г. Фәтхуллин